


*Шигырьләр, табышмаклар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004





## САНДУГАЧ

Сокланмый булдыра алмыйм,
Җырларын тыңлап туйгач:
Шундый тылсымлы кубызны
Ничек ясый сандугач?


«Миңа да серен әйтмәсме?»
Диеп тыңлаган булам.
Аның асыл җырларыннан
Үзем моң белән тулам!..



## МОНОЛОГ

Курчагымны уятырмын,
Утыртырмын каршыма.
Ул да: «Укыйсым килә! — дип, —
Мин тырыш!» — дисен миңа.

Мин аңа җырлар җырлатып,
Шигырьләр сөйләтермен,
Үзем кебек шәп укучы
Булырга өйрәтермен.





## ТЕЛЕФОННАН СӨЙЛӘШТЕК

Инглиз дустым телефоннан
Шалтыратты кичкырын,
Әмма аның сүзләренең
Аңламадым һичберен.

Шулай да, аз-маз сөйләшеп,
Уртак тел таптык икәү —
Аларда да «йокла!» сүзе
Безнеңчә «бай-бай!» икән.




## АВЫЛГА КАЙТКАЧ

Әби әйтә:
— Оланым!
Бабай әйтә:
— Боланым!

Шуңа бик тә
Шатландым —
Һәммәсен дә
Ятладым.







## ЯҢГЫРБИКӘ

Яңгырбикә биеп килә,
Кояш белән парлашып.
Бүген кояш кызын бирә —
Котлы булсын туй ашы!

И гаҗәеп бу йоланы
Кем генә уйлап тапкан?
Тәүге тапкыр күреп, аны
Шаян-туйга охшаткан?

Борын-борын заманнардан
Кем икәне билгесез.
Тик ышанам: сез бу туйга
Сөенешеп килерсез!



## КАЕНБАБАЙ

Каенага, каенишләр,
Каенэне, башкалар...
Әллә нинди каеннар бар —
Саный китсәң, күп алар.

Каената, каенана...
Каенбабай бар микән? —
Ул, мине сөеп, яратып,
Бер сыйпар иде биттән,
Кунакка кайтса читтән!..

## КАЗ БӘБКӘСЕ

Каз бәбкәсе тәпи-тәпи
Гөрләвек буйлап бара:
Имеш, минем кыланмышка
Син дә сокланып кара!

— Юк! Мин инде синең кебек
Тәртипсез бала түгел, —
Әниемә вәгъдә бирдем
Чиста йөрергә бүген.







## АТ КУЗГАЛАГЫ

Аттан кузгалак сорадым,
Ә ул фәкать кешнәде.
Аннан соң башын чайкады,
Китеп барды. Дәшмәде...

Ат кузгалагын сорадым
Хуҗасыннан ич — аттан!
Нигә соң әле абыйлар
Елмаеп калды арттан?






## ФИЛ

Зур әрекмән яфрагыдай
Аның һәрбер колагы.
— Сәлам, дускай! — диде бугай:
Миңа хортум болгады.

Бик мөлаем карашлары —
Дустым матур, сөйкемле.
Мин дә аңа кул болгадым,
Күптән таныш шикелле!




## КӨНГЕРӘ

Дәү сумкасы билдә булгач,
Бар җиргә дә өлгерә.
Заманага яраклашкан
Эшмәкәр бу — көнгерә.

Көне-төне чабып йөри,
Әллә ниләр майтара!
Шул ич инде бананнарны
Безнең якка кайтара.







## КРОКОДИЛ ӘФӘНДЕ

Яшел тере бүрәнә
Посып ята, күр әнә!
Сыйпыйм диеп,
кулың сузма,
Кәеф-сафасын бозма,
Чөнки яшел бүрәнә
Ерткыч икән, күр әнә:
Тешле авызын ачты да,
Су астына качты да,
Шуннан күзли корбанын.
Белдек хәйләсен аның!..
Менә сиңа бүрәнә —
Кереп күлнең түренә
(Усаллыгы тәмам җиткән),
Әрле-бирле йөренә.

## ЗЕБРА

Зебра — күрче! —
тельняшкасын
Гомере буена салмый.
Беләсезме? Ахрысы, ул
Үзен морякка саный!



## БӨРКЕТ

Читлектә булса да бөркет,
Карап узам гел өркеп.
Пәһлевандай көчле кошка
Бу тозаклар — йомычка...



## ЗООПАРК ТӨЛКЕСЕ

Әкиятләрнең күбесендә
Хәйләкәр, зирәк төлке.
Нинди хәйләкәр булсын ди,
Читлектә яшәп?
Көлке!..




## ДӨЯ

Кайчан гына карасаң да,
Сагызын чәйни дөя:
Шуңа мәллә өстән генә
Төкереп, борынын чөя?..

## КУЯНГА НӘСЫЙХӘТ

Куян керә бакчага
Тәмле кишер ашарга, –
Хуҗа-фәлән килеп чыкса,
Һәрчак әзер качарга.
И, куянкай, шаянкай,
Кермә лә син бакчага,
Бар син авыл кибетенә:
Кишерне ал акчага!
Йөрсәң шулай, кешеләрчә,
Даим тәүфыйк юлында,
Гел кибеттән кишер ашап,
Бетәр куркаклыгың да.






## КҮЛ

Ерак таудан караганда,
Күзге булып күренә!
Янына ук килеп баксаң,
Гап-гади бер күл генә...

## КЕРПЕ

Керпе яман чәнчесә дә,
Яманатын таратмыйм.
Мин энәләрдән шүрләмим,
Тик уколлар яратмыйм...






## ҮЛӘН БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Күзләр җиткәч, сары үлән
Пышылдый: — Үләм, үләм...
Аның моңсу зарын бүләм
Эндәшеп: — Дускай, сәлам!

— Синең,— дим,— күзгә төсеңә
Соклана бүген галәм!
Дөньядагы һәр кешегә
Син бүген — алтын келәм.








## ИМӘН ЧИКЛӘВЕГЕ

Җиргә өзелеп төшә:
— Тук!
Үзе эре, үзе тук.
Хәтта энәсе дә бар.
Җәнлек эзләнсә —
табар,
Тәмләп авызына кабар!



## ГӨМБӘ ҖЫЙГАНДА

Эзтабар кебек дикъкатьле
Булам хәтта арганда —
Гөмбәтабар дип йөртәләр
Мине көзге урманда.



## ЧАКМАТАШ

Чакматашка:
— Чакма! — диләр.
Әллә шуны белмиләр —
Ул чыгарган
очкын
чаккач,
Учаклар да дөрлиләр...



## ТӘҮГЕ КАР


Нигә, дисәң,
иртәдән
Сәламләде карга:
— Кар-р-р! —
Чыннан да бит бакчаларга
Бүген төшкән
тәүге кар.





## А ҺӘМ Ю ХӘРЕФЛӘРЕ

Аю, — дисәм, — олы җәнлек.
Юа — кечкенә кыяк...
Бинокльдән карагандай:
Зур як бар
            һәм кече як.



## ЧӘЧКӘЛӘР

Чәчкәләр төнгә ябыла,
Караңгылыктан өркеп.
Алар да
      кичен арыйдыр,
Безгә хуш исләр бөркеп.



## ТӘҮГЕ КАР ЯУГАЧ

**1**


Иртән бер ак затны күреп
Сәерсендем...
                    Карагач
Җентекләбрәк,
                    таныдым ла:
Карда үскән кар-агач!

**2**

Кар бөртеге учка иңә,
Ята тынып —
Гүя шушы мизгеленә
Ясин кылып...

**3**

Бүген җиһан шундый ак-ак.
Бәхетемә — йөрәк тар!
Хәтта иртә таңнан торып,
Карга да сөенә:
— Кар!!!



## МАННЫЙ ЯВА, КАР ЯВА

Көне буе манный ява —
Тишелгәнме әллә һава?
Хәтта җил белән шаярып,
Урамнар буйлап чаба.
Бер дә туктамый арып —
Юктыр ла аңа чама!
Әллә инде өстә бар
Манныйлы төпсез амбар?
И ява манный, ява —
Тишелгән мәллә һава?!



## ТИМЕРАЯК ШУГАНДА

Тимераяк кисә, Гата
Гел бозда аунап ята.
Кызык микән әллә аңа
Бозда егылып аунарга?
Моның сәбәбе гап-гади:
Өйрәнә ул
исерек булып
Спектакльдә уйнарга.





## ЯЗГЫ СОРАУ


Кар сулары, көн-төн агып,
Кайларга барып җитә?
Эрегән кар суын алып,
Гөрләвек кая китә?

Диңгезләргә китә ул, дип,
Апам миңа аңлата...
Карларның ядкаре булып
Бакчалар чәчәк ата!

## ЙОКЫ ЧҮЛМӘГЕ

— Йокы чүлмәге син, — диеп
Орышкалый әтием.
Әни әйтә:
— Син минем, — ди, —
Баллыкаем, тәтием…

Әни чүлмәк тәмен белә,
Әти әле белмәгән:
Кәнфиттән дә тәмлерәк ич
Минем йокы чүлмәгем!








## АРДЫМ

Бер адым,
ике адым:
Мин нәни бала —
ардым.
Карбызны,
кулдан
төшереп,
Төгәл икегә ярдым.
Шуның
бер өлешен
алып,
Бабам янына бардым:
— У-уф! — дидем аңа, —
ардым…

## ЧАБЫШ

Эт чаба мәче артыннан,
Бик тә ашыгып чаба…
Кая чабалар соң алар? —
Хуҗаларына таба!








## ШӘҮЛӘЛӘР

Минем шәүләм кара төстә,
Ә кояшныкы — ап-ак.
Ак дус кача
кара дустан,
Тап булган булып, уйнап!

Һәрчак алар менә шулай,
Берсен-берсе сагынып,
Көнозын йөриләр чабып,
Минем арттан тагылып.



## СӘЕР ХӘЛ

— Укып йөреп ярым-йорты,
Нигә мине алдадың?
Укытучың шалтыратты:
Тагын берле алгансың!

Әмма Гамил башын селки:
— Бүген юкка хурладың,
Начар билгем юк бит,
чөнки
Мин мәктәпкә бармадым...

## БОЛЫТ

Сулар коя, ут уйната,
Күк гөмбәзләрен ярып.
Кабат килгән
яңгыр алып
Болыт дигән зур Алып.

## ЭКСПЕРИМЕНТ

*(Диалог)*

— Әбекәем, бу тюбикта
Беләмсең күпме кершән?
— Белмим шул,
улым Хәсән.
— Ишектән өстәлгә чаклы
Җитә икән ул кершән,
Кысып чыгарып йөрсәң!..



## БАЙКАЛ

*(Нәни ачыш)*

«Байкал» диеп йөри идек, —
«Бай күл» икән исеме.
Чынлап та туры килә шул
Исеменә җисеме!

## ЯМАНСУ ГӨРЛӘВЕКЛӘР

Кояш назын җыя-җыя,
Чылтырашып актылар!
Язлар үтеп китү белән,
Күлгә кереп яттылар…





## КАСӘ

Кичә ишеттем яңа сүз:
«Бал белән тулган касә!» —
Түп-түгәрәк була икән
Бал өчен бәллүр кесә.



## ӘНИЕМ ЙӨРӘГЕ

— Барыгыз да йөрәгемдә! —
Диеп әйтә әнием.
Ничек аңа бишәү сыйдык? —
Йөрәк бигрәк нәни ул.





## СЫЕРЧЫК БУРАНЫ

### 1


Гүя кардан көртләр өя
Тупылдан туган буран.
Әллә инде кыш адашкан,
Әллә пакьләнгән урам?
Ак сихрилек уртасында
Сокланып басып торам:
Зураеп һәм матураеп
Киткән бер көндә урам!



## 2

Күлгә барып җиту белән,
Гүя чумдык ак бәскә.
Бу бит — сыерчык бураны,
Ничек аны белмәскә!

Көмештәй чал,
                тундай җылы, —
Җиргә сырылып ята.
Кышларны искә төшереп,
Аяк мамыкка бата.



## ИНЕШ

Җырлап узсам —
　　　　　җырлап кала,
Елап узсам — елап кала.
Инешкәем — сердәшем.
Тамчылары — күз яшем...
Аны гомер буе сагынам —
Мәңге сөям.
　　　　　Мәңге табынам!



# ТАБЫШМАКЛАР



* * *


Койрыгы өзелсә дә,
Кала ул һәрчак тере!
Мең кат зурайтсак, булыр
Крокодил кебек эре.

(*Кәлтә*)

* * *

Чәчәкләрдән чәчәкләргә
Көнозын оча-куна,
Нектар белән
тамак ялгап,
Чыклар белән юына!

(*Күбәләк*)





* * *


Зур алтын кыршау тәгәри
Көн саен һава буйлап.
Тупка да бик охшаган ул —
Кызганыч, булмый уйнап...

(*Кояш*)

* * *

Бар йөзләгән энәсе,
Әмма тегүче түгел...
Бер генә кәтүк булса да,
Җеп бүләк итәм бүген.

(*Керпе*)





* * *

Тылсымлы көмеш бөртекләр,
Галәмне төшкәч гизеп,
Минем учымда эриләр,
Йөрәк җылысын сизеп!

Алар йомшак, алар назлы —
Җиңгә мамыктай тула.
Кышкы салкын көннәрдә
Ужымга юрган була...


*(Кар)*

* * *

Бу кош
            бигрәк кыш ярата.
Җәй көне дә сорый: — Кар!
Үзе кара булгангамы,
Ак карсыз дөньясы тар.

*(Карга)*





* * *

Куяннар да җибәргәли,
Әбидән дә еш килә.
Аның белән бик мавыксаң,
Бик авырта теш кенә.

*(Конфет)*

* * *

Тышы — яшел, эче — кызыл,
Җылы якларда үсә.
Бигрәк баллы,
                        бигрәк сусыл! —
Исемен әйт әле, белсәң?

*(Карбыз)*





* * *

Аны кулга тот та син,
Ашлар ашарга ашык!
Бик тә җайлы,
бик тә кирәк —
Исеме аның — ...

*(Кашык)*



* * *

Кышын да искә төшереп
Җәйләрнең җылы чагын,
Ява мин теләгән чакта
Өйдәге мини яңгыр!

*(Душ)*



* * *

Озын яшел сөңге тотып,
Үсә җәен түтәлдә,
Ә кыш җиткәч,
бик файдалы
Томау белән ютәлдән.

*(Суган, сарымсак)*



* * *

Тыңлыйлар бу даһины
Сукыр тиен акчасыз.
Төннәр буе сайрый ул —
Бөек моңнар патшасы!

(*Сандугач*)



* * *

Башында үсә куак —
Шуны табып куандык.
Бу җәнлек безгә ошый:
Аның исеме — ...!

(*Поши*)



* * *

Күзен өнгә кереп яткач,
Суыра тәпиен генә.
Кышлар узып,
язлар җиткәч,
Чын күңелдән сөенә.

(*Аю*)



* * *

Сибәләп кенә уза,
Чиләкләп тә булгалый,
Кайчак кәефне боза,
Елмайтып та алгалый.
Өй түбәсен кага ул,
Тәрәзгә моңсу чиртә, —
Ерак сәфәргә аны
Зәңгәр болытлар илтә.

(Яңгыр)

* * *

Кояш керә, нурлар керә,
Җил-яңгырлар
узалмый.
Урамдагы һәр нәрсәне
Аның аша күзаллыйм.

(Тәрәзә)





* * *

Коеп яуган яңгырдан да
Курыкмый юлдаш-батыр:
Төймәсенә басу белән,
Өстемә кора чатыр!

(Зонтик)



* * *

Сыңар таҗлы кайнар чәчәк, —
Шырпы сызып терелтәм.
Әз-мәз генә җил өрсә дә,
— Үләм! — диеп дерелдәр...

(*Шам*)



* * *

Уйный ул дүрт кылда,
Тавышы — сокландыргыч!
Нәзек муенында
Дүрт нәни кара боргыч.

(*Скрипка*)



* * *

Җәй дә, көз дә, кыш та, яз да
Энәләре ямь-яшел.
Аның белән бергәләшеп
Яңа елга керерсең!
Бик теләсәң, кем икәнен
Кыш бабайдан белерсең.

(*Чыршы*)

* * *

Озынаяк, Озынкул —
Ак җиһанны даулый ул!
Таудан төшә очып кына,
Суза ике кыллы юл.

(*Чаңгычы*)





* * *

Тәне — агач,
 башы — күкерт:
Чырт итә, дөрләп китә.
Әгәр саксыз маташсаң,
Янгын да килеп җитә...

(*Шырпы*)



* * *


Сөйрәп йөри калканын,
Һәрдаим була юлда! —
Тыпырчынып, дүрт аяклы
Таш ята минем кулда...

(*Ташбака*)

* * *

Түшәмдә — пыяла алма.
Эченнән ут сирпелә.
Ансыз
 яшәп булмый һич,
Ул нәрсә дип йөртелә?

(*Лампочка*)



* * *

Алмаш-тилмәш
 өч күз яна:
Яшел, сары һәм кызыл.
Урамда исән йөрергә
Булыша ул көнозын.

(*Светофор*)





* * *

Йөзәр, меңәр чакрымнан
Тавышны ишеттерә, —
Югыйсә бит үзендә
Биш-алты тишек кенә.

*(Телефон)*



* * *

Кешеләр, аңа басып,
Суга карап еш тора.
Гомер буе
бер эштә ул —
Ярларны кавыштыра!

*(Күпер)*

* * *

Маңгаеннан тотып алып,
Тимер колагын борам.
Ә ул бөтен үпкәләвен
Эченә җыеп тора.
Вакыт җиткәч,
ачуыннан
Бик тә зәһәр кычкыра.

*(Будильник, уяткыч)*



* * *

Биш куышка — бер тишек,
Биш чоланга — бер ишек!
Салкыннарда
бик тә кирәк,
Әйтче, атала ничек?

*(Перчатка)*





* * *

Кояш-әтәч
иртә таңнан
Аларны йөри чүпләп…
Әмма кичкә таба алар
Кабат кабына күпләп!

(*Йолдызлар*)

* * *

Бер яктан —
ерак күрсәтәм,
Икенче яктан — якын:
Кырлы-мырлы түгел лә мин,
Шундый һәрвакыт холкым.

(*Бинокль*)





* * *

Тавышсыз,
кулсыз булса да,
Күп сүзле, күп рәсемле!
Нинди тылсымлы әйбер ул?
Син, дускай, беләсеңме?

(*Китап*)

* * *

Эшкә тотыныр алдыннан
Йотлыгып кара эчә.
Аннары ап-ак басуга
Яңа фикерләр чәчә.

(*Авторучка*)





*   *   *

Яшь айдай нәзек булса да,
Үләнне йөри турап,
Иген кырына да чыга
Тынгысыз тимер...

(*Урак*)



*   *   *

Зәңгәр угым төбәлгән
Котыпның үзәгенә:
Таба алам дөньяның
Һәрьягын үзем генә!

(*Компас*)

*   *   *

Бу ясалма тәрәзәгә
Дөнья хәлләре сыя.
Кичләрен ул
үз алдына
Бөтен гаиләне җыя.

(*Телевизор*)



*   *   *

Боз илендә —
иң зур җәнлек,
Йөри һәрчак ак тунда, —
Котып салкыны да тими,
Яшәгәч ул
гел шунда!

(*Ак аю*)





* * *

Тешләрен ыржайтып ята, —
Аңа басам, дип торма!
Басканның башына бәрә,
Ялгышкан өчен...

(*Тырма*)

* * *

Камышлар белән камалган
Түп-түгәрәк зәңгәр Нуль —
Балыклар да белми аның
Нәрсә икәнен: бу — ...

(*Күл*)





* * *

Бер сөенеп, бер көенеп
Карыйсыз йөзегезгә.
Таныйсызмы? Каршыгызда
Тылсымчы түгел — ...

(*Көзге*)



* * *

Бөтен тәнемне чапкалыйм,
Эссе бүлмәгә кереп.
Үз-үземне «кыйнаулардан»
Җаннарым китә эреп!

(*Мунча себеркесе*)



* * *

Күк йөзендәге моң-нокта
Уйный күңел сазында.
Сөенәбез! Коенабыз
Аның тылсым-назында!

(*Турай*)



* * *

Әнисенең кесәсендә
Баласының бишеге.
Җылы якларда яши ул,
Ничек аның исеме?

(*Кенгуру*)



* * *

Дөм караңгыда яши ул,
Җирне казый, эшкәртә, –
Бакчачылык сезонына
Үзеннән өлеш кертә.

(*Сукыр тычкан*)



* * *

Бу асыл кошлар турында
Йөзләгән җыр җырлана.
Җылы яктан почмак ясап
Очып кайта …

(*Торналар*)

* * *

Тәмләп ашагач ашын,
Кешнәп болгыйдыр башын.
Аны тану бик ансат:
Арбаны тарта, ул — …

(*Ат*)





* * *

Котып якның бер куышы
Яши безнең бүлмәдә, —
Аннан килә кыш сулышы
Хәтта җәйге челләдә.

(*Суыткыч*)

* * *

Вакытны гел барлап тора:
Көне дә, ае да бар!
Аңа карап, план корам,
Чөнки ул бит …

(*Календарь*)





* * *

Учлап-учлап утлы уклар чәчә
Җәйге күктә йөргән серле зат.
Дөбер-шатыр һава буйлап күчә,
Бөтен дөнья куя ялтырап.

(*Яшенле күк күкрәп*)

* * *

Әҗәл йөртә җилкәсендә
Бу хәтәр эш коралын...
Мин дә болыннарга чыгып,
Аны чарлап торамын.

(*Чалгы*)





* * *

Шикәр кебек ак,
Кардай сап-салкын,
Тарта үзенә
Балачак халкын!

(*Туңдырма*)

* * *

Болытчыкны кулга элеп,
Туендырам түтәлне,
Нинди ясалма яңгырның
Мин хуҗасы бу мәлне?

(*Сусипкеч*)





* * *

Ул, җил тегермәне булып,
Һавага күтәрелгән.
Кем шаярып күк түренә
Зур бөтерчекне элгән?

(*Вертолет*)

* * *

Корсагында су чыжылдый,
Түбәләрендә — төтен.
Өстәл түрендә гөрләсә,
Гаиләбез — бербөтен!

(*Самовар*)





* * *

Меңләгән яшел энәле
Күлмәктән,
безгә карап
Торадыр ул ямьле генә.
Аның исеме — ...

(*Нарат*)

* * *

Бик җитез, шаян, наян,
Әйтерсең лә ут йота.
Кичәге көнен токандай,
Үз койрыгын тота.

(*Песи*)





* * *

Галәмдә көмеш ыргактай
Тота төшәр чоңгылын.
Ул — мөселманлык билгесе,
Ул — мөкатдәс төн гөле!

*(Ай)*

* * *

Бу елгыр кара камчыга
Син һичкайчан кагылма, —
«Уйныйм!» диеп,
ахмак булып,
Көтмәгәндә чагылма!..

*(Зәһәр елан)*





* * *

Бу фонтан мәйданда тормый,
Диңгездә йөзеп йөри.
Су гизүче фонтанны,
Бәлки, беләсез сез дә?..

*(Кит)*



* * *

Филнең хортумы шикелле
Озын борынны алга сузып,
Ул тузаннан арындыра,
Һәр нәрсәне сайлап узып.


(*Тузансуыргыч*)


* * *

Мин дә, изге теләк юрап,
Кулыма каләм алам:
Хәл-әхвәлләрне язам да,
Кабат сагынып калам.

Һәм ышанам: көне-төне
Теләгем алга чабар —
Аяксыз да, канатсыз да
Дус йортына юл табар!

(*Хат*)





* * *

Һава хәлен гел белә ул,
Шул инде аның эше:
Көн җылытса — күтәрелә,
Суытса — аска төшә.
Урамга чыгар алдыннан
Аңа карый һәр кеше!

(*Термометр*)

* * *

Дүрт аяклы комбинат ул —
Мин аны бик яратам,
Чөнки чиләк-чиләк сөткә
Һәр көн безне баета.

(*Сыер*)



* * *

Көне буе кырда эшли:
Бар егәре, бар җаны!
«Тыр-тыр, пыр-пыр», —
диеп кешни.
Корыч ат, диләр аны.

*(Трактор)*





* * *

Дүрт көпчәкле, ике куллы,
Йөрткән йөкләре мулдан.
Тартучысы да тук булса,
Уза күптөрле юлдан.

*(Арба)*

* * *

Каракларадан коты очмый —
Исемен җисеме аклый:
Йортыңны, абзар-кураңны
Явыз затлардан саклый.

*(Йозак)*





* * *

Өебездә күптән яши
Нәни тимер тылсымчы:
Өс-башны пөхтәләндерә —
Һич калдырмый җыерчык!

*(Үтүк)*



# Эчтәлек


Сандугач . . . 2
Монолог . . . 2
Телефоннан сөйләштек . . . 3
Авылга кайткач . . . 3
Яңгырбикә . . . 4
Каенбабай . . . 5
Каз бәбкәсе . . . 5
Ат кузгалагы . . . 6
Фил . . . 7
Көнгерә . . . 7
Крокодил әфәнде . . . 8
Зебра . . . 8
Бөркет . . . 9
Зоопарк төлкесе . . . 9
Дөя . . . 9
Куянга нәсыйхәт . . . 10
Күл . . . 11
Керпе . . . 11
Үлән белән сөйләшү . . . 12
Имән чикләвеге . . . 13
Гөмбә җыйганда . . . 13
Чакматаш . . . 14
Тәүге кар . . . 14
А һәм Ю хәрефләре . . . 15
Чәчкәләр . . . 15
Тәүге кар яугач . . . 16
Манный ява, кар ява . . . 17
Тимераяк шуганда . . . 18
Язгы сорау . . . 19
Йокы чүлмәге . . . 20
Ардым . . . 21
Чабыш . . . 21
Шәүләләр . . . 22
Сәер хәл . . . 23
Болыт . . . 23
Эксперимент (*Диалог*) . . . 24
Байкал (*Нәни ачыш*) . . . 25
Ямансу гөрләвекләр . . . 25
Касә . . . 26
Әнием йөрәге . . . 26
Сыерчык бураны . . . 27
Инеш . . . 29

Табышмаклар . . . 30




УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
С 24

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссамы *Юлия Щетинкина*

**Сафин Мансур**

С 24 Сыерчык бураны: Шигырьләр, табышмаклар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 48 б.

Литературно-художественное издание для детей и юношества

*Сафин Мансур Габдуллович*

**СКВОРЦОВЫЕ МЕТЕЛИ**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.08.2004.
Форматы 70×100$^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. «Peterburq» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 3,90+фор.0,32. Шартлы буяу-оттиск 17,63.
Нәшер-хисап табагы 5,04+фор.0,47. Тиражы 5000 д. Заказ Э-577.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066.
Казан, Декабристлар ур.,2.

ISBN 5-298-01434-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2004